| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.02.2025 г.Казань № 22од

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган (2015 елның 22 декабрендәге 01-02/821 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге 01-02/265 номерлы, 2018

елның 9 гыйнварындагы 1од номерлы, 2018 елның 23 августындагы 91од номерлы, 2020 елның 4 декабрендәге 146од номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 123од номерлы, 2022 елның 29 апрелендәге 91од номерлы, 2024 елның 1 мартындагы 33од номерлы боерыклар белән кертелгән үзгәрешләр белән) исемлегенә, 4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«бөлгенлек (банкротлык) мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлек секторы мөдире;

административ штрафлар буенча керемнәрне администраторлау секторы мөдире».

Министр Р.И.Заһидуллин